Зур Кукмара авыл җирлеге Советы
Кукмара муниципаль районы Татарстан Республикасы

КАРАР

22 март 2024 ел №11

«Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында " 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Зур Кукмара авылы гражданнары җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Зур Кукмара авыл җирлеге Уставына, Зур Кукмара авыл җирлеге Советы
Карар кабул итте:

1. «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге Зур Кукмара авылында гражданнар җыенының гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча нәтиҗәләре турында» 24.11.2023 ел, №1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 05 апрелендә 13 сәгать 30 минутка билгеләргә» (2024 елның 30 гыйнварындагы 1 нче номерлы үзгәрешләр белән)

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылына 24.11.2023 №1 гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карарга үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Зур Кукмара авылының яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге, көндезге уку формасындагы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк булган кешеләрдән тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

1. Юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.
2. Вак таш түшәп, чокырларны төзекләндерү.
3. Зур Кукмара авылының урам-юл челтәрен карап тоту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.
4. Зур Кукмара авылында чишмәләр территориясен төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү.
5. Урамнарны яктырту өчен, энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру.
6. Балалар уен мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.
7. Су суырту башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су суырту башняларын ремонтлау, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, артезиан скважиналарын ремонтлау.
8. Зур Кукмара авылында Нурминкә елгасы аша Эшчеләр, М. Җәлил, Вахит, Октябрь, Колхоз, Х. Туфан, Елга аръягы урамнарына җәяүлеләр күперен төзекләндерү.

9. Яр буе зонасын карап тоту, мәчеттән алып Зур Кукмара стадионына кадәр җәяүлеләр күперен яшелләндерү һәм төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү.

10. Зур Кукмара авылында җәяүлеләр күперен төзү, проект документларын эшләү.

11. Зур Кукмара авылындагы «Быргы» чишмәсенә бара торган җәяүлеләр тротуарын төзекләндерү.

12. Зур Кукмара авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

13. Зур Кукмара авылы һәйкәлен төзү, ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документациясен эшләү.

14. Зур Кукмара авылында тукталыш павильоннарын буяу өчен буяулар сатып алу, проект-смета документларын эшләү.

15. Янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, янгын гидрантларын комплектлау, проект-смета документларын эшләү.

16. Ял зоналарын булдыру һәм төзекләндерү буенча чаралар үткәрү; Сабантуй бәйрәме уздыру урыны территориясен төзү һәм төзекләндерү.

17. Зур Кукмара стадионын яктырту алу һәм урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту.

18. Зур Кукмара авылында эскәмияләр һәм спорт инвентарьлары сатып алу, урнаштыру.

19. Яңа суүткәргеч челтәрләрен төзү, ремонтлау, проект-смета документациясен әзерләү, килешү буенча хезмәтләр һәм эшләр өчен түләү

20. Халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү

21. Зур Кукмара авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү

22. Зур Кукмара авылында автомобиль күпере төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру?

24.11.2023 елгы №1 карарында күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эшләр белән үзгәртү өлешендә:

**тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** (урамнарны яктырту өчен, энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру);

**су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (су суырту башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су суырту башняларын ремонтлау, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, артезиан скважиналарын ремонтлау; яңа суүткәргеч челтәрләрен төзү, ремонтлау, проект-смета документациясен әзерләү, килешү буенча хезмәтләр һәм эшләр өчен түләү)

**җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр)** (Зур Кукмара авылында чишмәләр территориясен төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү)

**яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту** (яр буе зонасын карап тоту, яшелләндерү, проект-смета документациясен эшләү)

**беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү** (янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, янгын гидрантларын комплектлау, проект-смета документларын эшләү)

**һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү** (Зур Кукмара авылы һәйкәлен төзү, ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документациясен эшләү)

**торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту** (юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыр.; Зур Кукмара авылының урам-юл челтәрен карап тоту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру; Зур Кукмара авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Зур Кукмара авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү; Зур Кукмара авылында автомобиль күпере төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру)

**тротуарлар төзү, ремонтлау** (Зур Кукмара авылындагы «Быргы» чишмәсенә бара торган җәяүлеләр тротуарын төзекләндерү)

**торак пункт территориясен төзекләндерү** (Балалар уен мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Ял зоналарын булдыру һәм төзекләндерү буенча чаралар үткәрү; Сабантуй бәйрәме уздыру урыны территориясен төзү һәм төзекләндерү; Зур Кукмара стадионын яктырту алу һәм урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту; Зур Кукмара авылында эскәмияләр һәм спорт инвентарьлары сатып алу, урнаштыру; халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү)

**тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру** (Зур Кукмара авылында тукталыш павильоннарын буяу өчен буяулар сатып алу, проект-смета документларын эшләү)

**торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өстендәге үтүләрне ремонтлау** (Зур Кукмара авылында Нурминкә елгасы аша Эшчеләр, М. Җәлил, Вахит, Октябрь, Колхоз, Х. Туфан, Елга аръягы урамнарына җәяүлеләр күперен төзекләндерү; мәчеттән алып Зур Кукмара стадионына кадәр җәяүлеләр күперен яшелләндерү һәм төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү; Зур Кукмара авылында җәяүлеләр күперен төзү, проект документларын эшләү)?

«КАРШЫ ТҮГЕЛ» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Зур Кукмара авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Ханафиев